КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 октябрь г.Казань № 949

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 4 март, 135 нче карары белән расланган Өйдә яки медицина оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне оештыру өлешендә дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасы һәм озак дәвалануга мохтаҗ белем алучыларның, шулай ук инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) арасында мөнәсәбәтләрне регламентлаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өйдә яки медицина оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне оештыру өлешендә дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасы һәм озак дәвалануга мохтаҗ белем алучыларның, шулай ук инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) арасында мөнәсәбәтләрне регламентлаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 4 март, 135 нче карары белән расланган Өйдә яки медицина оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне оештыру өлешендә дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасы һәм озак дәвалануга мохтаҗ белем алучыларның, шулай ук инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) арасында мөнәсәбәтләрне регламентлаштыру һәм рәсмиләштерү һәм рәсмиләштерү тәртибенә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 4 март, 135 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 31 октябрь, 949 нчы карары редакциясендә)

# Өйдә яки медицина оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне оештыру өлешендә дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасы һәм озак дәвалануга мохтаҗ белем алучыларның, шулай ук инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) арасында мөнәсәбәтләрне регламентлаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Мәгариф турында федераль закон), «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә өйдә яки медицина оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем алу хокукын гамәлгә ашыру максатларында һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан өйдә яки дәүләт медицина оешмасында башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне оештыру өлешендә дәүләт яки муниципаль гомуми белем бирү оешмасы һәм озак дәвалануга мохтаҗ белем алучыларның, шулай ук сәламәтлеге хәленә бәйле рәвештә белем бирү оешмасына (алга таба шул ук эзлеклелектә – белем бирү оешмасы, белем алучылар, төп гомуми белем бирү программалары, медицина оешмасы) йөри алмаган инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) арасында мөнәсәбәтләрне рәсмиләштерү процедурасын билгели.

1.2. Өйдә яки медицина оешмасында белем бирүне оештыруга хокук бирә торган авырулар исемлеге Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

1.3. Өйдә яки медицина оешмасында белем алучыларны укыту көндезге, көндезге һәм читтән торып яисә читтән торып уку формасында, шулай ук төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруның челтәр формасын кулланып гамәлгә ашырылырга мөмкин. Белем бирү оешмасы мәгариф өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда электрон белем бирү, дистанцион белем бирү технологияләрен кулланырга хокуклы.

1.4. Өйдә яки медицина оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча укыту, белем бирү оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган мәгариф программаларының дәрәҗәсен һәм юнәлешен исәпкә алып, тиешле белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар тарафыннан билгеләнә торган дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен үтәүгә каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла.

## II. Өйдә укытуны оештыру

2.1. Өйдә укытуны оештыру өчен белем алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) белем бирү оешмасына түбәндәгеләрне тапшыра:

белем алучының ата-анасының берсеннән (законлы вәкиленнән) белем алучыны өйдә яки медицина оешмасында укытуга күчерү турында язма гариза (алга таба – гариза);

медицина оешмасының өйдә яки медицина оешмасында укытуны оештыру кирәклеге (мондый укыту чорын күрсәтеп) турында бәяләмәсе (медицина белешмә кәгазе).

Белем алучының ата-анасы (законлы вәкиле), җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программасы буенча укытуны оештыру өчен психологик-медик-педагогик комиссиянең бәяләмәсе кирәк булганда, федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелгән, инвалидлыкны билгеләү фактын раслый торган белешмә кәгазен һәм инвалид дип танылган гражданны карап чыгу актыннан өземтәне, инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын тапшырырга хокуклы.

2.2. Өйдә белем алу өчен нигез – гариза һәм әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар кергән датадан алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә белем бирү оешмасының белем алучыны өйдә укуга күчерү турында чыгарыла торган боерык бирү характерындагы акты һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча Мәгариф турында федераль законның 54 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты нигезендә уку турында шартнамә (булганда).

2.3. Белем бирү оешмасы, белем алучының ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, өйдә укыту һәм тәрбияләү өчен шартлар тудыра:

белем алган вакытта дәреслекләр һәм уку әсбаплары, шулай ук укыту-методик материаллар, белем һәм тәрбия бирү чаралары түләүсез файдалануга бирелә;

белем алган вакытта махсус дәреслекләр, уку пособиеләре һәм дидактик материаллар, күмәк һәм индивидуаль файдаланыла торган махсус техник укыту чаралары (сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар өчен) түләүсез файдалануга бирелә, шулай ук сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче хезмәтләре түләүсез күрсәтелә;

педагогик хезмәткәрләр арасыннан белгечләр белән тәэмин итә, төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерү өчен кирәкле методик һәм консультатив ярдәм күрсәтә;

психологик-медик-педагогик комиссиянең бәяләмәсе нигезендә, белем алучының үзенчәлекләрен һәм белем алу ихтыяҗларын исәпкә алып, төп гомуми белем бирү программалары буенча яки җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча өйдә индивидуаль укытуны оештыра (сәламәтлекләренең

мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен);

белем алучыларның арадаш аттестациясен оештыруны һәм уздыруны гамәлгә ашыра, белем алучыны дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерләүне оештыра һәм анда катнашуын тәэмин итә;

дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән белем алучыга тиешле дәрәҗәдәге белем алу турында документ тапшыра.

2.4. Белем бирү оешмасы һәм белем алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) арасындагы мөнәсәбәтләр белем бирү оешмасының уставы, әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар, белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән регламентлаштырыла.

2.5. Өйдә укытуны оештыру индивидуаль укыту планы буенча үткәрелә, ул боерык бирү характерындагы актка яки укыту турындагы шартнамәгә кушымта (булган очракта) булып тора һәм белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль эшләнә.

2.6. Өйдә белем бирү һәм тәрбия бирү барышы федераль дәүләт мәгариф стандартлары таләпләре һәм федераль төп гомуми белем бирү программалары нигезендә, психологик-медик-педагогик комиссия тәкъдимнамәләре нигезендә эшләнә торган төп гомуми белем бирү программасы (булган очракта) белән регламентлаштырыла.

Төп гомуми белем бирү программасына түбәндәгеләр керә:

җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программасының (алга таба – махсус индивидуаль үсеш программасы) тиешле дәрәҗәсен гамәлгә ашырганда, белем алучының индивидуаль уку планы яки махсус индивидуаль үсеш программасы;

календарь уку графигы;

уку дәресләренең индивидуаль расписаниесе (көндезге уку формасы);

уку-укыту консультацияләренең индивидуаль расписаниесе (читтән торып уку формасы);

гамәлгә ашырыла торган төп гомуми белем бирү программасы нигезендә уку предметларының, курсларның, дисциплиналарның (модульләрнең) эш программалары;

белем бирү оешмасының индивидуаль укыту планы буенча, шул исәптән өйдә белем бирү тәртибен регламентлаштыра торган локаль норматив актлары турында белешмәләр (әлеге Тәртип белән җайга салынмаган өлештә);

агымдагы өлгерешне контрольдә тоту, арадаш аттестация уздыру дәвамлылыгы, формалары һәм тәртибе.

Индивидуаль уку планы яки махсус индивидуаль үсеш программасы, уку дәресләренең һәм укыту консультацияләренең индивидуаль расписаниеләре белем бирү оешмасы тарафыннан белем алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) белән килештерелә һәм белем бирү оешмасының боерык бирү характерындагы акты белән раслана.

2.7. Атналык белем бирү йөкләнешенең максималь гомуми күләме федераль дәүләт белем бирү стандартлары, федераль төп (җайлаштырылган төп) гомуми белем бирү программалары таләпләре, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, сәламәтләндерүне һәм аларның ялын оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» СП 2.4.3648-20 номерлы

санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары белән билгеләнә.

2.8. Кайбер уку предметларын өйрәнү өчен белем алучыларга белем бирү оешмасына бару медицина оешмасының рөхсәт кәгазе белән рөхсәт ителә.

2.9. Төп гомуми белем бирү программасы (җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программасы) буенча индивидуаль уку планын гамәлгә ашырганда уку елы Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары – башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2021 елның 22 мартындагы 115 номерлы боерыгында билгеләнгән сроклар нигезендә белем бирү формасына карап башлана.

Уку елының тәмамлану датасы индивидуаль уку планы яки махсус индивидуаль үсеш программасы белән билгеләнә.

Уку елының башлану (тәмамлану) турында мәгълүмат тиешле дәрәҗәдәге белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасына кушымта булган календарь уку графигында күрсәтелә.

2.10. Өйдә уку өчен кайбер предметлар буенча атнага бер сәгатьлек йөкләнеш күләмен билгеләү, белем алучыларның индивидуаль үзенчәлекләрен һәм психофизик мөмкинлекләрен исәпкә алып, белем бирү оешмаларының уку планнары, индивидуаль уку планнары яки махсус индивидуаль үсеш программалары нигезендә билгеләнә.

Дәресләр вакыты белем алучылар һәм (яки) аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) белән килештерелә.

2.11. Белем алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) өйдә укытуны оештыру өчен (белем алучының эш урынын оештыруны кертеп) шартлар тудыра һәм белем алучыны кирәкле язу әсбаплары белән тәэмин итә.

2.12. Белем алучыны өйдә укытуны оештыруны озайту өчен аның ата-анасы (законлы вәкиле (законлы вәкилләр)) ел саен чираттагы уку елы башына гариза һәм медицина оешмасының мондый уку чоры күрсәтелгән, өйдә төп гомуми белем бирү программалары буенча укыту турында тәкъдимнамә бирелгән бәяләмәсен (медицина белешмә кәгазен) тапшыра.

## III. Медицина оешмаларында укытуны оештыру

3.1. Медицина оешмасында укыту түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

турыдан-туры дәвалануны, сәламәтләндерүне гамәлгә ашыручы һәм төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукына лицензиясе булган медицина оешмасының махсуслаштырылган структур белем бирү бүлекчәсе (алга таба – медицина оешмасының махсуслаштырылган структур бүлекчәсе) базасында;

белем алучы даими укый торган белем бирү оешмасында укуын дәвам итү өчен барлык хокукларын саклап, медицина оешмасында булган чорда белем алучы кабул ителә торган медицина оешмасының урнашу урыны буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасы тарафыннан;

медицина стационары шартларында озак дәвалануга мохтаҗ белем алучылар өчен челтәр рәвешендә гамәлгә ашырыла торган белем бирү программасын төзеп һәм

медицина оешмасы ресурсларын (белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бүлмәләр, табибларның уку йөкләнеше эчтәлеге һәм күләме, белем алучының агымдагы сәламәтлек торышын исәпкә алып, белем бирү программасына төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнамәләр һ.б.) һәм белем бирү оешмасы ресурсларын (педагогик кадрлар, уку-укыту эш программалары, укыту чаралары, дидактик материаллар, электрон белем бирү ресурслары һ.б.) берләштереп, белем алучы даими укый торган белем бирү оешмасы тарафыннан.

Белем алучыны медицина оешмасының махсуслаштырылган структур бүлекчәсенә яки медицина оешмасының урнашу урыны буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасына укырга күчерү ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) сайлавы буенча Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан билгеләнгән белем алучыны башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер оешмадан тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга күчерүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.2. Медицина оешмасында укытуны оештыру өчен нигез – белем алучы даими укый торган белем бирү оешмасының укырга керү датасыннан эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә белем алучыны медицина оешмасына укырга яки медицина оешмасында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасына укырга күчерү турында һәм түбәндәге документлар нигезендә чыгарыла торган боерык бирү характерындагы акты:

медицина оешмасының медицина оешмасында 21 көннән артык дәвалану яки медицина реабилитациясе (көндезге стационарны кертеп) узу турында бәяләмәсе;

бала озак дәвалануда булачак медицина оешмасы җитәкчесе исеменә аны укытуны оештыру үтенече белән гариза.

3.3. Белем алучының медицина оешмасына кергәндә дәресләр башлану датасын дәвалаучы табиб, бүлек мөдире белән берлектә, медицина картасында тиешле язу ясала торган сәламәтлек торышына карап билгеләнә.

Дәресләр чорына белем алучыга карата медицина оешмасы тарафыннан аның сәламәтлеге торышы буенча укырга рөхсәт ителмәгән чор кертелми.

3.4. Медицина оешмасы, санитария кагыйдәләре һәм нормативлар таләпләрен, шулай ук гамәлгә ашырыла торган төп гомуми белем бирү программасын (җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программасын) исәпкә алып, уку өчен шартлар тудыра.

Белем алучылар медицина оешмасында укыган вакытта медицина оешмасы тарафыннан яки медицина оешмасының урнашу урыны буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасы тарафыннан бирелә торган дәреслекләрдән һәм уку әсбапларыннан, шулай ук уку-укыту һәм методик материаллардан, укыту һәм тәрбия бирү чараларыннан файдалана.

Белем алучылар язу-сызу әйберләре белән белем алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан тәэмин ителә.

3.5. Белем бирү барышы төркем белән үткәрелә торган һәм индивидуаль дәресләр рәвешендә оештырыла.

Индивидуаль дәресләр түбәндәгечә уздырыла:

бер кешедән өч кешегә (өч кешене кертеп) кадәр булса;

хәрәкәтләнү мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән белем алучылар өчен;

дәвалаучы табиб бәяләмәсе буенча ятак режимындагы белем алучылар өчен.

3.6. Медицина оешмасында белем бирү һәм тәрбия бирү барышы төп (җайлаштырылган төп) гомуми белем бирү программасы белән регламентлаштырыла, шул исәптән түбәндәгеләрне үз эченә ала:

федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре һәм федераль төп гомуми белем бирү программалары нигезендә эшләнә торган төп гомуми белем бирү программаларын;

федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре һәм федераль җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары һәм психологик-медик-педагогик комиссиясе бәяләмәсе (сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен) нигезендә, ә инвалидлар өчен шулай ук инвалидның индивидуаль тернәкләндерү яки абилитацияләү программасы нигезендә эшләнә торган җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларны;

белем алучының ата-аналары (законлы вәкилләре) белән, имзаларын куйдырып, медицина оешмасының бүлек мөдире һәм дәвалаучы табибы белән килештерелгән һәм белем бирү оешмасының боеру характерындагы акты белән расланган индивидуаль уку планын (белем бирү оешмасы тарафыннан эшләнгән индивидуаль уку планы буенча индивидуаль дәресләрне оештырганда);

уку предметларының, курсларның, дисциплиналарның (модульләрнең) эш программаларын (индивидуаль уку планы буенча укытуны оештырганда);

белем бирү оешмасы тарафыннан белем алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) белән берлектә эшләнгән уку дәресләренең (көндезге уку формасы) һәм укыту консультацияләренең (читтән торып уку формасы) индивидуаль расписаниесен;

медицина яки белем бирү оешмасының индивидуаль уку планы буенча укыту тәртибен (әлеге Тәртип белән җайга салынмаган өлешендә), белем алучының агымдагы өлгерешен контрольдә тотуны, арадаш аттестациясен үткәрү дәвамлылыгын, формасын һәм тәртибен регламентлаштыра торган локаль норматив актларын.

3.7. Атналык белем бирү йөкләнешенең максималь гомуми күләме федераль дәүләт белем бирү стандартлары, федераль төп (җайлаштырылган төп) гомуми белем бирү программалары таләпләре, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү һәм укыту, сәламәтләндерүне һәм аларның ялын оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» СП 2.4.3648-20 номерлы санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары белән билгеләнә.

3.8. Медицина оешмасындагы белем алучыны укыту медицина оешмасы һәм медицина оешмасының урнашу урыны буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасы яки белем алучы даими укый торган белем бирү оешмасы арасында төзелгән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.9. Белем бирү барышы медицина оешмасында озак дәваланучы (реабилитация узучы) белем алучыларны укытуны оештыру турында шартнамә төзелгән белем бирү оешмасында эшләүче педагогик хезмәткәрләр яисә медицина оешмасының махсуслаштырылган структур белем бирү бүлекчәсенең педагогик хезмәткәрләре

тарафыннан башкарыла.

3.10. Медицина оешмаларында балаларны укытуны гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре бурычларын җайга сала торган локаль норматив актларда һәм документларда педагогларның һәм укучыларның сәламәтлеген яклауга юнәлдерелгән санитария-гигиена режимын һәм санитария кагыйдәләрен үтәү күздә тотыла.

Шул ук вакытта, дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып, гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашырганда көндезге формада белем алучыларга тьютор ярдәме тәкъдим ителә.

3.11. Паллиатив медицина ярдәме алучы балаларны укытуны оештыру озак дәвалануга мохтаҗ балаларны укытуны оештыруга карата гомуми алымнар, баланың индивидуаль махсус ихтыяҗлары картасы нигезендә һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тәкъдимнамәләре нигезендә гамәлгә ашырыла. Үсешендә күп санлы авыр бозылышлары булган әлеге төркем балалары Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән федераль җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары һәм махсус индивидуаль үсеш программасы нигезендә белем ала. Паллиатив медицина ярдәме күрсәтелүче үсешендә күп санлы авыр бозылышлары булган балаларны укытуны оештырганда махсус коррекцияле педагогиканың методик ресурсы кулланыла.

3.12. Белем алучыларны укытуны оештыру максатларында медицина оешмасы дәресләр уздыру өчен белем бирү оешмасына урын бирә һәм медицина оешмасының махсуслаштырылган структур бүлекчәсендә белем бирүне оештыру һәм гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруны тәэмин итә.

3.13. Дәвалану чорында медицина оешмасында белем алучылар турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), туу датасы, яшәү урыны, белем алучы даими укый торган белем бирү оешмасының исеме), уку предметлары буенча дәресләрнең саны һәм эчтәлеге, төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерүнең индивидуаль нәтиҗәләре, арадаш аттестация, сыйныфтан сыйныфка күчерү, йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре һәм белем бирү оешмасын тәмамлау турында мәгълүмат тиешле сыйныф (электрон) журналында күрсәтелә.

3.14. Медицина оешмасында дәвалану чорында белем алучылар алар даими укый торган белем бирү оешмаларының статистика хисапларында исәпкә алына.

3.15. Белем алучыларның арадаш аттестациясен оештыру һәм үткәрү белем бирү оешмасының яки медицина оешмасының махсуслаштырылган структур бүлекчәсенең локаль норматив акты белән регламентлаштырыла.

3.16. Медицина оешмасыннан өземтә алганда белем алучыларга, аларның уку предметларын үзләштерү нәтиҗәләрен һәм уку срокларын күрсәтеп, белешмә кәгазе бирелә.

Белешмә кәгазе белем бирү оешмасы җитәкчесе яки медицина оешмасының махсуслаштырылган структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Дәвалану тәмамлангач, белем алучының ата-аналары (законлы вәкилләре) ул даими укый торган белем бирү оешмасының җитәкчесенә дәвалануның тәмамлану сроклары, белем бирү оешмасына кайтуы һәм укуны дәвам итәргә әзер булуы турында алдан хәбәр итә. Белем бирү оешмасында (көндезге, читтән торып, көндезге

һәм читтән торып уку) яки өйдә уку формаларын билгеләгәндә белем алучының ата-аналары (законлы вәкилләре) дәвалаучы табибның (медицина консилиумының) эпикриз өземтәсендә теркәлгән медицина тәкъдимнамәләренә, белем алучының стационардан чыгару вакытына гомуми психофизиологик торышына, медик-социаль экспертиза бәяләмәләренә һәм психологик-медицина-педагогик комиссиянең инвалид балаларга һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга (әгәр андый балалар булса) карата тәкъдимнамәләренә таянып эш итә.

3.17. Дәүләт йомгаклау аттестациясе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

Дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы узган затларга тиешле дәрәҗәдәге белем алу турында документлар бирелә.

3.18. Белем бирү оешмасы Россия Федерациясе законнары нигезендә эшләнгән белем бирү оешмасының локаль норматив акты нигезендә медицина оешмасында белем бирүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

Медицина оешмасының махсуслаштырылган структур бүлекчәсе Россия Федерациясе законнары нигезендә эшләнгән медицина оешмасының локаль норматив акты нигезендә медицина оешмасында белем бирүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

3.19. Медицина оешмасында белем алучыларның белем бирү программаларын үзләштерүне контрольдә тоту белем алучы даими рәвештә укый торган белем бирү оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.